Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

№ 4 01 ноябрь 2024 ел

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Федоровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларын, контракт буенча хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1.Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Федоровский торак пункты чикләрендә юл полотносын төзү, шул исәптән: туфрак күтәрү, вак таш сатып алу, вак таш сибү, тигезләү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү , торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту, шул исәптән: кар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы Аксубай районы Федоровский поселогының Үзәк урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында уздырырга.
4. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы | А.В.Макаров

СОВЕТ
НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ